ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.09.2023 Мөслим авылы № 404

**Суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган гражданнарга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентларын раслый торган Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карарларын юкка чыгару турында**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган гражданнарга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслаучы карарлар үз көчен югалткан дип санарга:

1.1. - «Муниципаль берәмлекләрнең опекадагы гражданин мөлкәте белән алыш-бирешләр кылуга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентынраслау турында» Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 23 июнендәге 343 номерлы карары;

1.2. - «Муниципаль берәмлекләр тарафыннан опекадагы гражданин мәнфәгатьләрендә гомерлек рента шартнамәсен төзүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 23 июнендәге 346 номерлы карары;

2. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасары М.Р. Бәдретдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Салихҗанов**